# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге  Зур Сукаеш торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**08 ноябрь 2024 ел** **№ 2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сукаеш авыл җирлеге Зур Сукаеш торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2025 елда Сукаеш авыл җирлеге Зур Сукаеш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан , гаилә әгъзасы мобилизацияләнгән, хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән һәм махсус хәрби операциягә җибәрелгән гаиләләрдан тыш 400 сум күләмендә һәм 2 Төркем инвалидларыннан, 80 яшьтэн өлкәннәрдэн 200 сум сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүг буенча  түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- Зур Сукаеш авыл җирлегендә урамнарны яктырту өчен лампаларны, яктырткычларны, электр җиһазларын һәм махсус җайланмаларны сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәт күрсәтү;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Молодежная урамында, Садовая урамында, Советская урамында, Школьная урамында вак таш салу, торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту буенча чит оешмаларның хезмәт күрсәтүләре, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (трактор йөртүченең юлларны кардан чистарту, торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту буенча чит оешмаларның хезмәтләре өчен түләү, эшләр өчен килешү буенча түләү);
- ремонт, киртәләр кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (җәйге вакытта үлән чабу , ягулык-майлау материаллары, триммер өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү).

3. Әлеге карарны,  кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Сукаеш авыл җирлеге мәгълүмати стендларында тбәндәге адрес буенча: Зур Сукаеш авылы, Совет ур., 30 йорт, һәм  Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru)  урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Сукаеш авыл җирлеге башлыгы Закирова З.Җ.